**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

**2023елның 23 октябре** **40 номер**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның 20 декабрендәге 38 номерлы Урта Девятово авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Урта Девятово авыл җирлеге Советы **карар чыгарды**:

1. «Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның **20 декабрендәге 38** номерлы Урта Девятово авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуныүз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Урта Девятово**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Ипатова К.М**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы*
*Урта Девятово авыл җирлеге Советының*
*2023 елның 23 октябрендәге 40 номерлы*
*карарына кушымта*

**«Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2011 елның 20 декабрендәге 38 номерлы Урта Девятово авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

1) **12 статьяның 10 пунктында**
- "Интернет" челтәрендә" сүзләрен "рәсми сайтларда" сүзләренә алмаштырырга;

2) **15 статьяның 1 абзацы**

- «һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга, «хезмәткәрләр,»сүзеннән соң «ведомство буйсынуындагы оешмалар хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

3) **1 пунктның 7 статьясында**

- «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә .